ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# "Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннары квоталау һәм резервлау турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 21 маенда
кабул ителде

**1 статья**

"Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннары квоталау һәм резервлау турында" 2006 елның 24 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 7 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 7) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"1) квота – эш бирүче тарафыннан эшкә урнаштырылырга тиешле инвалидларны эшкә алу өчен эш бирүче хезмәткәрләренең исемлектәге уртача саныннан процентларда билгеләнгән эш урыннары саны;";

2) 3 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"3 статья. **Инвалидларны эшкә урнаштыру өчен квота һәм махсус эш урыннарының минималь санын билгеләү тәртибе**

1. Хезмәткәрләренең саны 100 кешедән артыграк булган эш бирүчеләргә инвалидларны эшкә алу өчен квота хезмәткәрләрнең исемлектәге уртача саныннан 2 дән 4 процентка кадәр күләмдә билгеләнә. Хезмәткәрләренең саны 35 кешедән ким булмаган һәм 100 кешедән артык булмаган эш бирүчеләргә инвалидларны эшкә алу өчен квота хезмәткәрләрнең исемлектәге уртача саныннан 3 процент күләмендә билгеләнә.

2. Инвалидларның иҗтимагый берләшмәләре һәм устав (җыелма) капиталы инвалидларның иҗтимагый берләшмәсе кертемнәреннән торган алар оештырган оешмалар, шул исәптән хуҗалык итү ширкәтләре һәм җәмгыятьләре булган эш бирүчеләр инвалидларны эшкә алу өчен билгеләнгән квотаны үтәүдән азат ителәләр.

3. Эш урыннарын мәҗбүри квоталаудан үзләренә карата законнарда билгеләнгән тәртиптә ябу турында карар кабул ителгән юридик затлар (оешмалар) булган эш бирүчеләр азат ителәләр.

4. Квотаны планлаштырганда, инвалидлар категориясенә кертелгән хезмәткәрләр биләп тора торган эш урыннарының саны исәпкә алына.

5. Инвалидларны эшкә алу өчен квотаны исәпләп чыгарганда хезмәткәрләрнең исемлектәге уртача санына хезмәт шартлары буенча эш урыннарына аттестация үткәрү яисә хезмәт шартларын махсус бәяләү нәтиҗәләре буенча зарарлы һәм (яисә) куркыныч хезмәт шартларына кертелгән хезмәт шартлары булган хезмәткәрләр кертелми.

6. Дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар хезмәткәрләренең исемлектәге уртача санына федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары, муниципаль норматив хокукый актлар нигезендә вазыйфага сайлап кую, тиешле вазыйфаны биләүгә конкурс буенча сайлап алу, вазыйфага билгеләнү яисә вазыйфага раслану юлы белән биләнә торган вазыйфалар керми.

7. Квота, тиешле территориядә хезмәт базарындагы барлыкка килгән вәзгыятьтән чыгып, кимендә бер календарь елга билгеләнә.

8. Квота кертү турында эш бирүчеләргә ул кертелә башлаганчы кимендә ике ай алдан хәбәр ителә.

9. Эш бирүчеләргә билгеләнгән квота кысаларында инвалидларны эшкә урнаштыру өчен махсус эш урыннарының минималь саны билгеләнә.

10. Квота һәм инвалидларны эшкә урнаштыру өчен махсус эш урыннарының минималь саны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслый торган нигезләмәдән чыгып билгеләнә.";

3) 4 статьяның 1 өлешендә "3 статьясындагы 2 өлешендә күрсәтелгән оешмалардан тыш" сүзләрен "3 статьясындагы 2 һәм 3 өлешләрендә күрсәтелгән оешмалардан тыш" сүзләренә алмаштырырга;

4) 5 статьяның 2 өлешендә "3 статьясындагы 2 өлешендә күрсәтелгән оешмалардан тыш" сүзләрен "3 статьясындагы 2 һәм 3 өлешләрендә күрсәтелгән оешмалардан тыш" сүзләренә алмаштырырга;

5) 6 статьяның 1 өлешендәге 3 пунктында "оешмада" сүзен төшереп калдырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2014 елның 9 июне
№ 43-ТРЗ